Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 45-ТРЗ

"Татарстан Республикасы Түбән Кама<br>районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча<br>Татарстан Республикасы җәмәгать<br>судьяларының суд участоклары чикләре<br>турында" Татарстан Республикасы Законына<br>кушымта

**Татарстан Республикасы Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Түбән Кама муниципаль районының Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы, Ялантау, Кармалы, Макаровка, Түбән Уратма, Сосновка, Иске Чишмә һәм Ширәмәт авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Корабельная һәм Вокзал урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә узучы автомобиль юлына кадәр бара, алга таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә баручы автомобиль юллары тоташкан җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, аннары әлеге ноктадан алып туп-туры көнбатышка таба, Ильинка торак пункты территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Түбән Кама муниципаль районының Кама елгасы акваториясендә урнашкан чигенә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк юнәлештә Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге, Каенлы авыл җирлеге һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап Чаллы – Чистай һәм Түбән Кама – Балчыклы автомобиль юлларының күчәр

сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары суд участогы чиге төньяк-көнчыгышка таба Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча Первопроходцы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк юнәлештә Первопроходцы урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне (Төзүче поселогының Үзәк урамында урнашкан йортларны) кертеп, төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап Вокзал урамы, Төзүчеләр проспекты һәм автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл чишелешенә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Вокзал урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге территориясе керә.

## 3 нче суд участогы

3 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Корабельная һәм Вокзал урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап Корабельная урамындагы 30 нчы йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм автомобиль юлы буенча әлеге йортның төньяк-көнбатыш ягы буйлап аның төньяк почмагына кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба борыла һәм Химиклар проспектындагы 29 нчы йортның төньяк-көнчыгыш ягы буйлап, әлеге йортны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Тукай урамы буйлап, шул ук исемдәге бакча территориясен һәм так якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вокзал урамы, Төзүчеләр проспекты һәм автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл чишелешенә кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Вокзал урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 4 нче суд участогы

4 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар проспекты һәм Тукай урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Тукай урамы буйлап шул исемдәге бакча аша, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Төзүчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр проспекты, Вокзал урамы һәм төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан боҗралы юл чишелешенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгышка таба автомобиль юлының көньягы буйлап Первопроходцы урамы белән кисешкәнче бара, алга таба Первопроходцы урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне (Төзүчеләр поселогының Якты урам, Бакчалы һәм Беренче төзүчеләр урамнарында урнашкан йортларны) кертеп, Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы белән кисешкәнче уза, алга таба көнбатыш юнәлештә Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама муниципаль районы чигенә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба суд участогы чиге төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан урман массивын кертеп, автомобиль юллары тоташкан урынга кадәр уза, аннары сулга борыла һәм гомуми юнәлештә көнбатышка таба Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, боҗралы автомобиль юллары чишелешенә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама шәһәре юнәлешендә узучы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Актүбә урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Актүбә урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамындагы 5 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көнбатышка таба Октябрьнең 50 еллыгы урамы буйлап Лемаев исемендәге бакча аша, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тукай урамындагы 40 нчы йорт янында урнашкан ноктага кадәр бара.

## 5 нче суд участогы

5 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар проспекты, Бакый Урманче

һәм Октябрьнең 50 еллыгы урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектындагы 31 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм әлеге йорт һәм Корабельная урамындагы 30 нчы йорт, Химиклар проспектындагы 31 нче йортны да кертеп, арасындагы автомобиль юлы буйлап уза, алга таба Химиклар проспектындагы 29 нчы йортның төньяк-көнчыгыш ягы буйлап Корабельная урамындагы 30 нчы йортның төньяк почмагына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм әлеге йортның төньяк-көнбатыш ягы буенча автомобиль юлы буйлап Корабельная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Корабельная урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә баручы автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Ильинка һәм Дмитриевка торак пунктлары юнәлешендә баручы автомобиль юллары тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба әлеге ноктадан алып туп-туры көнбатышка таба, Дмитриевка торак пункты территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан Түбән Кама муниципаль районы чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк юнәлештә Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге, Красный Ключ авыл җирлеге һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба суд участогы чиге көньякка таба Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап урман массивы кырыена кадәр уза, аннары уңга борыла һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Сөембикә урамы юнәлешендә узучы грунтлы юл белән кисешкәнче бара, алга таба әлеге грунтлы юл буйлап көньяк-көнчыгышка таба, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә урамы белән кисешкәнче уза, аннары шул ук юнәлештә Сөембикә һәм Бакый Урманче урамнарының күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспекты, Бакый Урманче һәм Октябрьнең 50 еллыгы урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр уза.

**6 нчы суд участогы**

6 нчы суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар һәм Вахитов проспектларының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты һәм Мурадьян урамының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспектындагы 66/2 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза,

аннары уңга борыла һәм көнбатышка таба автомобиль юлы буенча Тынычлык проспектындагы 64 нче йортның көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 66/2 нче йортны кертеп, Сөембикә урамындагы 14 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм автомобиль юлы буенча Чулман урамындагы 7, 5, 3, 11 һәм 9 нчы йортларның төньяк-көнбатыш ягы буйлап, Сөембикә урамындагы 36, 38 нче йортларны һәм Чулман урамындагы 15 нче йортны кертеп, Чулман урамының күчәр сызыгы белән кисешкәнче бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Чулман урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба Сөембикә урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бакый Урманче урамының һәм Тынычлык проспектының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Бакый Урманче урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

6 нчы суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Сухарево авыл җирлеге территориясе керә.

## 7 нче суд участогы

7 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык, Вахитов проспектлары һәм Мурадьян урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньякка таба Мурадьян урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, уза, урман массивы алдына барып җитә, аннары сулга борыла һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Сөембикә урамы юнәлешендә узучы грунтлы юл белән кисешкәнче уза, алга таба әлеге грунтлы юл буйлап, сул якта урнашкан автомобиль кую урыны территориясен һәм йортларны кертеп, Сөембикә урамы белән кисешкәнче бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Чулман урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман урамындагы 15 нче йортның көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм автомобиль юлы буйлап Чулман урамындагы 15 нче, Сөембикә урамындагы 38, 36 нчы йортларның көньяк-көнчыгыш ягы аша, Чулман урамындагы 9, 11, 3, 5 һәм 7 нче йортларны кертеп, Сөембикә урамындагы 14 нче йортның көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба автомобиль юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба, Тынычлык проспектындагы 64 һәм 58 нче йортларны кертеп, Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкәнче уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспекты һәм

Мурадьян урамы белән кисешкән урында урнашкан бoжралы юл чишелешенә кадәр бара.

**8 нче суд участогы**

8 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Вахитов, Тынычлык проспектлары һәм Мурадьян урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шинниклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкәнче уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Шинниклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бызов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Бызов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Урманлы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Урманлы урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы һәм "Шинник" су-спорт базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм  төньякка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, су-спорт базасы территориясен кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көнбатышка таба "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба суд участогы чиге көньякка таба Түбән Кама – Красный Ключ автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Мурадьян урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Мурадьян урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык һәм Вахитов проспектлары белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

8 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Красный Ключ һәм Прости авыл җирлекләре территорияләре керә.

**9 нчы суд участогы**

9 нчы суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Химиклар һәм Вахитов проспектларының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шинниклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Шинниклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Бызов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән

ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба Бызов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Урманлы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Урманлы урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

**10 нчы суд участогы**

10 нчы суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Менделеев урамы һәм Химиклар проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамындагы 5 нче йорт янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Октябрьнең 50 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, Лемаев исемендәге бакча территориясен һәм җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

10 нчы суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Афанас авыл җирлеге территориясе керә.

**11 нче суд участогы**

11 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гагарин һәм Менделеев урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Спорт урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Спорт урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны (Актүбә торак пункты) кертеп, Актүбә урамына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Актүбә урамының күчәр сызыгы буйлап төзелеш индустриясе базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап божралы автомобиль юллары чишелешенә кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Чаллы – Чистай әйләнгечле автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм

төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Вахитов проспектына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба, аннары төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

11 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге территориясе керә.

## 12 нче суд участогы

12 нче суд участогы чигенә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Урман урамы һәм Химиклар проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Урман урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Менделеев урамы һәм "Шинник" су-спорт базасы юнәлешендә узучы автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньякка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Кама елгасының сул ярына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Кама елгасы акваториясендә урнашкан "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап "Түбән Кама шәһәре" муниципаль берәмлеге, Прости авыл җирлеге һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба Түбән Кама муниципаль районы чиге буйлап Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба суд участогы чиге төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Түбән Кама автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан урман массивы һәм сәнәгать зонасы территорияләрен кертеп, Вахитов проспектына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Вахитов проспектының күчәр сызыгы буйлап Менделеев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба, аннары төньяк-көнбатышка таба Менделеев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Химиклар проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Химиклар проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Урман урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

12 нче суд участогы чигенә Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак һәм Шәңгәлче авыл җирлекләре территорияләре керә.